| | |
|---|---|
| ГЛАВА<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«КУАКБАШСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«КУАКБАШ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023елның 30 октябрендә №2

Лениногорск муниципаль районы Куакбаш авыл җирлегенең Куакбаш авылында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Куакбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24.1 статьясы нигезендә, Лениногорск муниципаль районы «Куакбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы КАРАР БИРДЕ:

1.2023елның 18 ноябренә Лениногорск муниципаль районы Куакбаш авылы җирлегендә гражданнарның үзара салымы чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнарның җыенын 13 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2.Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

Сез 2024 елда үзара салым кертүне Лениногорск муниципаль районының Куакбаш авыл җирлеге Куакбаш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, көндезне бүлектә укучы студентлардан тыш, һәр балигъ булган кешедән алынган средстволарны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкаруны хәл итүгә юнәлдерүгә 500 (Биш йөз) сум күләмендә билгеләү белән килешәсезме:

2.1) торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- Куакбаш авылында (Совет урамы, Ленин урамы, М. Җәлил урамы, Х. Такташ урамы, К. Маркс урамы, Маяковский урамы, Тукай урамы, Сәйдәшев урамы, Г. Исхакый урамы, Яшьләр урамы) юлларны кардан чистарту

2.2.) Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин иту:

- Куакбаш авылында янгын сүндерү машинасы өчен җылы боксны җылыту

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә: Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Куакбаш авылы

К. Маркс урамындагы җирле үзидарә бинасы, 15 йорт, Сходнево-Чертанлы авылында Азатлык урамындагы авыл клубы бинасында, 5б йорт, Чуте авылында Тынычлык урамындагы авыл клубы бинасында, 8а йорт, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru/) бастырырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Куакбаш авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы Р.Р.Әхмәтҗанова